# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2006 елның 17 мартындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

1) халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең билгеләнгән таләпләргә туры килүенә республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру;

2) күпфатирлы йортларга техник документациянең һәм шундый йорт белән идарә итүгә бәйле башка документларның сакланышын тәэмин итүгә республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру.”;

2) 10 статьяда:

а) 1 пунктта “дәүләт вәкаләтләрен” сүзләре алдыннан “халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең билгеләнгән таләпләргә туры килүенә республика дәүләт торак күзәтчелеген башкару буенча” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

“2) Татарстан Республикасының дәүләт торак күзәтчелеге органы – күпфатирлы йортларга техник документациянең һәм шундый йорт белән идарә итүгә бәйле башка документларның сакланышын тәэмин итүгә республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә үтәлүе өлешендә түбәндәге юллар белән:

дәүләт вәкаләтләренең үтәлүе турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген шушы орган тарафыннан ел саен раслана торган план нигезендә күчмә тикшерүләр, шулай ук кирәк булган саен планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү;”;

в) 2 һәм 3 пунктларны тәңгәл рәвештә 3 һәм 4 пунктлар дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 76-ТРЗ